ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә, шулай ук хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Татарстан Республикасында хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының $5^1$ статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2026 елның 22 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

«Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә, шулай ук хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2012 елның 13 гыйнварындагы 9-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 1; 2013, № 5, № 10; 2015, № 7 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2020, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2023, № 81 (I өлеш); 2026, № 1 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) преамбулада «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы,» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасында хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2019 елның 27 декабрендәге 120-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы,» сүзләрен өстәргә;

2) кушымтада:

а) 6 пунктта:

2 пунктчада «хайваннар өчен булган приютка» сүзләрен «хайваннарны вакытлыча тоту пунктына» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктчада «хайваннар өчен булган приютта» сүзләрен «хайваннарны вакытлыча тоту пунктында» сүзләренә, «хайваннар өчен булган приютларга» сүзләрен «хайваннарны вакытлыча тоту пунктларына» сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктчада «Россия Федерациясе законнарында һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 9 пунктта «хайваннар өчен булган приютка» сүзләрен «хайваннарны вакытлыча тоту пунктына» сүзләренә алмаштырырга, «хайваннар өчен булган приютта» сүзләрен «хайваннарны вакытлыча тоту пунктында» сүзләренә алмаштырырга, «Россия Федерациясе законнарында һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) 11 пунктта:

бишенче абзацта «хайваннар өчен булган приютка» сүзләрен «хайваннарны вакытлыча тоту пунктына» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче абзацта «хайваннар өчен булган приютта» сүзләрен «хайваннарны вакытлыча тоту пунктында» сүзләренә алмаштырырга;

тугызынчы абзацта «Россия Федерациясе законнарында һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

г) 14 пунктта:

беренче абзацта «хайваннар өчен булган приютка» сүзләрен «хайваннарны вакытлыча тоту пунктына» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «хайваннар өчен булган приютка» сүзләрен «хайваннарны вакытлыча тоту пунктына» сүзләренә алмаштырырга;

д) 15 пунктның беренче абзацында «хайваннар өчен приютка» сүзләрен «хайваннарны вакытлыча тоту пунктына» сүзләренә алмаштырырга;

е) 16 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

$$«HPt_i^0 = \frac{[K_i x K_i^m]}{5} x Hpt ,»;$$

дүртенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$K_i^m$ – i-муниципаль берәмлеге өчен ауланырга тиешле хуҗасыз хайваннар саны нормативыннан элек яшәгән җирләренә кире кайтарылырга тиешле хуҗасыз хайваннар өлеше, 0,8 гә тигез;»;

ж) 17 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

$$«HPl_i = K_i x K_i^m x Hpl ,»;$$

з) 18 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18. I-муниципаль берәмлеге өчен хайваннарны вакытлыча тоту пунктында хуҗасыз хайваннарны тотуга норматив чыгымнар түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$HPc_i = (K_i x K_i^m x20 + K_i x(1 - K_i^m) x10) x Hpc ,$$

монда:

20 – хайваннарны вакытлыча тоту пунктына китерелгән хуҗасыз хайваннарны аларда йогышлы авырулар булуны ачыклау максатыннан мәҗбүри карантинга ябу өчен (10 календарь көн), шулай ук хайваннарны вакытлыча тоту пунктында хуҗасыз хайваннарны операциядән соң тоту өчен (10 календарь көн) кирәкле календарь көннәр саны;

1 – өлеш эквивалентында күрсәтелгән тулы зурлыгындагы $K_i$;

10 – хайваннарны вакытлыча тоту пунктына китерелгән хуҗасыз хайваннарны аларда йогышлы авырулар булуны ачыклау максатыннан мәҗбүри карантинга ябу өчен кирәкле календарь көннәр саны;

*Нрс* – хайваннарны вакытлыча тоту пунктында бер хуҗасыз хайванны бер календарь көн дәвамында тоту чыгымнарының социаль стандартлар һәм табигый нормалар белән билгеләнгән нормативы, сумнарда.»;

и) 19 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

$$«HPk_i = K_i x K_i^m x Kжх Hpk_s + K_i x K_i^m x Kмх Hpk_k\ ,»;$$

к) 20 пунктта:

беренче абзацта «Россия Федерациясе законнарында һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

$$«HPm_i = K_i x(1 - K_i^m) x Hpm\ ,».$$

**2 статья**

«Татарстан Республикасында хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2019 елның 27 декабрендәге 120-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $5^1$ статьясына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2020, № 4 (I өлеш), № 26 (I өлеш); 2021, № 93 (I өлеш); 2022, № 77 (I өлеш); 2023, № 86 (I өлеш); 2025, № 1 (I өлеш); 2026, № 1 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«$5^1$ статья. **Татарстан Республикасы территориясендә хуҗасыз хайваннарга карата мөнәсәбәт буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыргандагы чаралар исемлеге**

Татарстан Республикасы территориясендә хуҗасыз хайваннарга карата мөнәсәбәт буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыргандагы чараларга түбәндәгеләр керә:

1) хуҗасыз хайваннарны аулау, шул исәптән аларны транспортировкалау һәм хайваннарны вакытлыча тоту пунктларына кичектергесез тапшыру;

2) хуҗасыз хайваннарны Федераль законның 16 статьясындагы 7 өлеше нигезендә хайваннар приютларында тоту;

3) хуҗасыз хайваннарга карата дәвалау-профилактика чаралары үткәрүне (шул исәптән вакцинацияләү, дегельминтизацияләү, дезинсекцияләү), аларны стерильләштерүне (кастрацияләүне) дә кертеп, хайваннарны вакытлыча тоту пунктларында хуҗасыз хайваннарны тоту;

4) югалган хайваннарны хуҗаларына кире кайтару, шулай ук хайваннар приютларына яки хайваннарны вакытлыча тоту пунктларына китерелгән хуҗасыз хайваннарга яңа хуҗалар эзләү;

5) сәбәпсез агрессивлык күрсәтми торган хуҗасыз хайваннарны элек яшәгән җирләренә әлеге статьяның 3 һәм 4 пунктларында күрсәтелгән чараларны үткәргәннән соң кире кайтару;

6) әлеге Законның $5^2$ статьясындагы 1 һәм 2 өлешләрендә билгеләнгән очракларда хуҗасыз хайваннарны юк итү;

7) Федераль законның 18 статьясындагы 7 һәм 8 өлешләре нигезендә башка чаралар.».

**3 статья**

Әлеге Закон 2027 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2026 ел, 25 июль
№ 48-ТРЗ